Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ДЕКАБРЬ * 2021 * КАЗАН

12



Александр АЛЁШИН

Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ

АЛДЫНГЫЛЫК

Исләр-тәмнәр сизмәс булдык,
Ишетмәс вә күрмәс булдык,
Мең яндык вә мең кат туңдык,
Без яңадан, гүя тудык.

Кунакларга йөрмәс булдык,
Кибетләргә кермәс булдык,
Биткә борынчаклар тактык –
Төчкермәс вә "өрмәс" булдык.

Вакциналар сынау өчен,
Җанлы савыт – кисмәк булдык,
Җылы эзләп тәрәз кагар
Ку-ар-кодсыз песнәк булдык.

Биологик коралларга
Бирешмәдек, "үлмәс" булдык.
Якыннарны җирли-җирли
Шаярмас вә көлмәс булдык.

Тик шулай да бәйрәм булса,
Мәйданнарга гөрләп тулдык.
Өйгә кайткач хәмер кушып,
Битне-кулны уып юдык.

Җиңел яшәү юлын эзләп
Җиңел-җилпе, иләс булдык.
Кайда хаклык, кайда ялган
Һич берсенбер белмәс булдык.

Түрә-кара нәрсә әйтсә,
Ни кушсалар – шуны кудык.
Булдырабыз! Булдырдык без!
Без алдынгы – шул бар булдык!

Ни кушсалар – шуңа күндек,
Ни әйтсәләр – шуны белдек.
Ахыр чиктә һәммәбез дә
Күккә аштык, җиргә сеңдек.

• • •

Алмаз ХӘМЗИН

Ә тегеләр...
ә тегеләр...
Беләсез инде кемнәр?..
Үзләрен фиргавен, диеп,
Аллага тиңләүчеләр:
Бездәйләрне чүпкә чутлап,
Соры корттай байлык туплап,
Дөньяның артына тибеп,
Җир-ананың нефтен имеп,
Газын-суын читкә сатып,
Хәрам малның согын татып,
Кызу комда кызынып ятып,
Чибәрләргә күзен атып,
Аң-акылларыннан шашып,
Чит илләрдә банк ачып,
Салымнардан читтә качып,
Яталар тик корсак кашып...

Илдар НӘФИЕВ



ШОМБАЙ
болай диде...



Хөрмәтле Чаян! Хәзер матбугат чаралары безнең түрәләрнең төрле шикле, ә кайчагында мәгънәсез белдерүләрен чәйнәргә яраталар: имеш, дәүләт сезгә бала тудырырга кушмаган, бәяләр ошамый икән – күбрәк эшләргә кирәк... Ә кайчак башка төрле әйберләр дә ишетергә туры килә. Мәсәлән, күптән түгел казанлыларны «Водоканал»ның генераль директоры Андрей Егоровның әйткән сүзләре тетрәндерде: «Миңа беркем дә ышанмый, мин дә бит суны краннан эчәм!»

Ф. ШӘРИПОВА

КАЗАН

Укучыбызның хаты Шомбай аганы бик кызыксындырды.

– Бу яхшы гадәтне башка начальниклар да куллануга алсалар, шәп булыр иде, – диде аксакалыбыз. **– Транспорт хуҗаларына шыгрым тулган автобусларда йөреп карарга, сәламәтлек саклау башлыкларына чиратларда иза чигәргә, депутатларга законнарны үтәргә, ә чәнечкеле чыбык артында хуҗа булып утыручыларга төрмә хастаханәләрендә ятып карарга...**

Александр ШУЛЬПИНОВ

Әсхать ФӘСХЕТДИНОВ

ЯШӘСЕН "ЧАЯН" ЖУРНАЛЫМ

Журналымда кызык кешеләр эшли:
Мәсхәрче дә, мәзәк язучы.
"Чаян"ыбыз үзе дә бит
Бар нәрсәдән кызык табучы.

Сатирасы – лаекларның
Күрмәгәнен күрсәтә.
"Кәкре" юлдан барганнарның
Холыкларын үзгәртә.

Карикатуралар карасаң,
Бар да тормыштагы хәл.
Кайсылары гыйбрәт була,
Кайсысы – ару мәкаль.

Бик яратып укыйбыз без
Һәрбер санын журналның.
Табиблардай дәвалый ул
Бозыкларын дөньяның.

Яшәсен "Чаян" журналым,
Чәчәк атсын гомергә!
Себереп атып чүп-чарларны,
Ямь өстәсен гел җиргә!





Анатолий НЫРОВ



Кибет караклары

Әле күптән түгел генә товар белән сатып алучы арасында кырыс сатучы тутәй кыяфәтен алган үтмәслек киртә тора иде. Начар яткан әйберләрнең иясе булу бәхете бик сирәк кешегә һәм, кагыйдә буларак, арткы ишек аша гына тәти иде. Базар икътисады үз шартларын тәкъдим итте, һәм кибет караклары бәхетенә товарны тотып карау гына түгел, ә сиздермичә генә кесәгә шудырту мөмкинлеге бирүче гипер, супер, мини һәм башка маркетлар барлыкка килде. Барыбызга да билгеледер, ике пандемия елы эчендә урлашу бөтен юнәлешләрдә дә үсте, һәм кибетләрдән әйбер чәлдерү күренеше дә моннан читтә калмады. Әгәр элек кулга чиста булмаган бәндәләрне кыйммәтле алкоголь, сыр, затлы ит продуктлары һәм кофе ныграк кызыксындырган булса, хәзер исә урлашуга һәвәс кулланучылар култык асларына тавык, кер юу порошогы, чипсы кыстырып чыгарга күп сорамыйлар. Сәүдә хезмәткәрләре бу үзгәрешне халыкның фәкыйрьлеккә тәгәрәве белән аңлаталар. Булганына риза булырга туры килә...

Яшел Үзәндә язның бер төнендә Төзүчеләр урамындагы супермаркетка бер ир килеп керә. Кулына әрҗә ала да, эшчән кыяфәт белән кибет киштәләрен өйрәнә башлый. Тик менә кибеттә аннан башка да кеше булу мөмкинлеге аның башына килми. Ремонтчылар бу турыда полициягә хәбәр итәләр, һәм төнге кунакны тиешле урынга алып китәләр. Ә менә Казанда бер яшь пар көпә-көндез эш итә. Алар 5 мең сумлык продуктлар тутырган ике сумканы касса янынннан алып чыккан чакта эләгәләр. Ике очракта да ачлык белән бәйле гамәл җинаять эше белән тәмамлана. Мондый мисаллар җитәрлек, ләкин аларның барысы да судка барып җитми, каракларның күбесе шунда ук тиешле акчаны түләүне хәерлерәк күрә.


Мондый вак урлашуны кешечә аңларга буладыр, бәлки. Ләкин кырыс суд җәлләүнең нәрсә икәнен белми. Узган ел Саба районында яшәүче берәүгә кибеттән 1200 сумлык товар шудырткан өчен өч ел каты режимлы колония "чәпиләр". Кеи әйтмешли, аермасын тоясыздыр...

Әмма кайчагында урлашуның сәбәбен хокук саклау органнарына гына түгел, хәтта үзләренә аңлата алмаучылар да очрый. Казанда ике сәрхуш, адашыптырмы, Шаһиди урамындагы туй салонына килеп керәләр. Шунда берсен шайтан котырта. Ул берничә күлмәкне эләктереп ала да табан ялтырата. Аның теләген аңлау кыен, тик урам буенча чабучы, кулына ап-ак туй күлмәкләре тоткан кырынмаган исерек ерак китә алмый... Чаллыда да шундый гадәти булмаган хәл була. Анда 46 яшьлек ир киосктан 10 кап туңдырма урлап, аларны урамда өләшеп йөри. Бу татлы гамәлнең максаты әлегәчә сер булып кала...

Ә сәүдәне иң зур югалтуларга шоплифтер дигән сырлы сүз белән аталгаган караклар дучар итә. Бу – кибеттән товарларны заказ буенча урлау юнәлеше. Аларга теләгән төс һәм размердагы киемгә заказ бирү җитә һәм син үзеңне аның иясе дип саный аласың. Заказ бирүченең акчасы башта "гарант" дип аталган "хуҗа абзый"га тапшырыла, һәм товар "сатып алучы"га барып җиткәч кенә башкаручыга барып җитә. Шоплифтерлар бик оста эшлиләр, һәм аларны эләктерү чипсы каракларын тотуга караганда, күпкә катлаулырак булыр...

Кибет караклары белән көрәш бер генә минутка да туктап тормый. Дистәләгән еллар буе дәвам иткән каршы тору барышында кибет киштәләре тирәсендәге активлыкны киметер өчен, күп кенә ысуллар барлыкка килде. Ләкин иң яңа технологияләр дә кешенең чиксез бай фантазиясен һәм йоклаган намусын уздыра алмый. Шуңа күрә урлашу нәтиҗәсендә мөмкин чыгымнар алдан ук товарның бәясенә кертеп куела. Чөнки сәүдә статистикасы буенча, ун уңышлы урлашуга бер генә уңышсызы туры килә. Нәтиҗәдә, кибетнең барча криминаль чыгымнарын сатып алучы түли...

Людмила ЧАЩИНА



Александр АЛЁШИН

Ринат АБЗАЛОВ



Михаил ЛАРИЧЕВ



Игорь КИЙКО





• • •

– Өч көн буе кырмыска оясын күзәтәм...

– Шуннан?

– Бернинди киңәшмәләр, планнар ору юк. Шуңа карамастан, барысы да эштә!

• • •

Ел шактый уңышлы узды. Ике төр товар гына кыйммәтләнде: азык-төлек һәм көнкүреш товарлары.

• • •

– Карагыз әле, бу психбольницамы? Сезнең барлык авыруларыгыз урынындамы?

– Ә нәрсә булган?

– Хатыным ниндидер бер тиле белән качты!

• • •

Һәр сәясәтчегә туган көнендә аңа әйтелгән бөтен нәрсәнең аның турында уйланылган әйберләр белән туры килүен телисе килә!

• • •

– Мин монда даһи бер табиб таптым! Өч минут эчендә ул минем хатынны барлык авырулардан терелтте.

– Ничек итеп?

– Ул аңа барлык авыруларны якынлашып килүче картлык галәмәте, дигән.

• • •

– Нигәдер, миңа сезнең ютәлегез ошамый!

– Гафу итегез, доктор, минем башка ютәлем юк...

Икенче көнне.

– Менә бүтәнчә! Ютәлегез хәйран әйбәтләнгән!

– Тырыштым инде – төне буе күнегүләр ясадым!

• • •

Супермаркеттагы сакта торучы:

– Битлекләрне онытмыйбыз...

– Әлбәттә! Шәп комедия...

• • •

Белдерү:

Тәрбияче кирәк. Бала бик тыныч, компьютерга өйрәтелгән.

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Әгәр ир белән хатын бергә яшәмәсә, уңышлы никахлар ешрак очрар иде.

Салымнар турында сүз барганда патриотизм юкка чыга.

Без яшәмибез – яшәргә җыенабыз гына.

Чибәр хатыннар – күзаллау сәләте булмаганнар өчен.

Кеше үзе битараф булган әйберләр белән генә ризалаша.

Кеше гомере – мәхәббәт өчен артык озын нәрсә.

Бөтен кеше дә озак яшәргә тели. Ләкин беркем дә картаерга теләми.

Кешене яшьләрдән зарланудан да ныграк картайткан нәрсә юк.

(Тормыш белгечләре мәҗлесендә язып алынды)


Михаил ЛАРИЧЕВ






Александр АЛЁШИН

Валерий ТАРАСЕНКО









АЛГА КИТЕШ

Татарстан түрәләре ришвәтчелек өлкәсендә сизелерлек активлаштылар. Соңгы ел эчендә алар арасында мондый җинаятьләр саны бер ярым тапкыр артты. Дәүләт чиновниклары һәм муниципаль хезмәткәрләр арасында 280 нән артык тикшерү уздырылды, 254 очракта кагыйдә бозу очраклары ачыкланды, ә 242 түрә җавапка тартылды. Тик алга китеш коррупциягә каршы көрәшчеләрдә дә күзәтелә. Әгәр узган ел ришвәтчеләрнең 88 проценты гына җавапка тартылган булса, хәзер бу сан 95 процентка җитте.

УРТА ТЕМПЕРАТУРА

Республикабыз башкаласында уртача хезмәт хакы 54 мең сумга кадәр арткан, бу – әлбәттә, отчётлар буенча. Әмма сораштырылган казанлыларның 70 проценты мондый акчаны гомерләрендә дә күргәннәре юк дип белдергәннәр – аларның керемнәре кешечә яшәргә дә җитми. 57 процент чыгымнарын киметергә мәҗбүр, ә һәр өченче казанлы өстәмә эштә эшли. Ирләр – ремонт, төзелеш өлкәсендә, шәхси автомобильләрендә кеше йөртү белән мәшгуль. Ә хатын-кызлар исә тәрҗемә, текст җыю белән шөгыльләнә. Менә шундый – "хастаханә буенча урта температура"...

ШОМА ТУТАШ


Казан банкларының берсендә эшләүче хезмәткәр туташ берничә ай буе кибетләрдә әйбер сатып алганда кеше акчасын түләгән. Шулай берзаман туташка банк картасын алыштыру өчен клиент мөрәҗәгать иткән. Ул чакта сиздермичә генә клиент счётыннан 3 мең сумны шудырткан. Соңыннан, карта хуҗасына хәбәр итми генә, картаны тагын бер тапкыр яңарткан һәм өч ай буе аның белән файдаланып йөргән. Яшь "банкир" гаебен таныган, акчаның бер өлешен кайтарып та биргән, әмма барыбер шартлы рәвештә ике елга хөкем ителгән.

ХӘЙЛӘКӘР ФАТИР БИЛӘҮЧЕ

Бөгелмәдә берәү бер ел буе социаль найм буенча фатирда яшәгән. Торакны калдырып китәргә вакыт җиткәч, анда яшәүче белән бергә фатирдан бөтен сантехника, газ плитәсе һәм хәтта радиаторларның да юкка чыкканлыгы ачыкланган. Ләкин фатир биләүче хәйлә уйлап чыгарган: ул полициягә торакны басу турында гариза язган. Тик хокук сакчылары фатирны "зыян күрүче" үзе "чистарканны" тиз төшенгәннәр. Хәйләкәрне хәзер, матди зыян китерү өстенә, ялган донос язуда да гаеплиләр.



Валентин ДРУЖИНИН



• • •

Бәяләр тәмам бәйдән ычкынып, ялгыз пенсионерлар шешә җыеп йөри торган көннәрнең берсендә авыру карчык табибка кергән. Тегесе, сораша-сораша, аны бик озак караган, аннары киңәшләр бирә башлаган:

– Сезгә, әбекәй, йомырка, симез ит, майлы шулпа ашарга ярамый...

– И улым, – дип бүлдергән әби, – шуларның берсен генә ашап торсам да, беркайчан монда килеп йөрмәс идем!..



Николай ВОРОНЦОВ

Әхәт САФИУЛЛИН

ВИАГРА

Бөтенесе виаградан башланды. Туктале, мәйтәм, беркөнне телевизор карагач, моны кулланып карыйм!.. Нәрсә булган ди сиксән яшьлек миндәй егеткә! Күңелем белән мин шундый бит, виагра булышыр, юкка әйтмәгәндер телевизор тапшыруындагы врач! Бу хәлне ишетү белән, хатын бармагын чигәсенә терәп, боргычлап куйды.

– Кара, син, нәрсә уйлаган бит карт тиле – аңа виагра кирәк! Бөтенләй ычкынган, акылыннан язган!

Беләм: акча җәлли. Ләкин мин җавабын таптым: "Дөньяда ике тапкыр яшәмибез, әйдә, кулланып карыйк әле соң булса да!"

Дару шәп булып чыкты. Беренче төнне үк сиздем. Карчыгым минем кочаклауларымнан, иркәләүләремнән үлә язды. Әйтерсең лә яшь чаклары исенә төште. Кысып-кысып үптем дә әле, хәтта сөякләре шытырдады. Ә менә тегесе – юк! Мөгаен, нәрсәдер кушканнар.

Иртән аякларыма басмак булам, ә алар тотмый. Мамык кебек йоп-йомшак. Врач чакырттык. Дару язды. Дәваланам: көндез аяктан дару кабам, ә төнгә виаграныкын йотам. Менә шулай һәр көн! Аякларым ныгыды. Ә тегесе – селкенми дә!

Җитмәсә, бил ычкынды карчыкны кочаклаганда. Иелә дә алмыйм! Врач чакырттык. Рецепт, дарулар... Кайберләрен эчәм, кайберләре белән сөртенәм. Ә төнгә – виагра. Ниһаять берничә көннән соң бил рәтләнде. Ә тегесеннән – хәбәр дә юк!

Кинәт баш авырта башлады. Әйтерсең лә кемдер тимер белән нидер казына. Врач килде. Рецепт, дарулар... Көндез баш авыртудан таблетка кабам, ә төнгә – виагра. Әһә, баш рәтләнде. Ә тегесе – нитми!

Инде төчкерәм. Бертуктаусыз. Дүрт көн буе. Врач кирәк. Рецепт, дарулар...

Карчык виагра турында мыгырдый:

– Ташла теге нәмәстәңне әчүне!

Врач та шулай ди.

Туктаттым. Атна чамасы үтте микән, төчкерү бетте. Кәеф тә күтәрелде. Ә теге – юк!



Илдар НӘФИЕВ



Виктор ФЁДОРОВ



Василий АЛЕКСАНДРОВ

Дамир МОРТАЗИН

Уңышлы тәкъдим

Администрация башлыгы Дөмбаев урынбасарларын киңәшмәгә җыйды. Беренче эш итеп үзенең алагаем йодрыгы белән өстәл төеп куйды. Чакырылганнар, сискәнеп, башларын түбән иде.

– Нәрсә, килеп җиттекме?! Әйттем бит мин сезгә, кирәкне бирәчәкләр әле! – дип.

Башлар тагын да түбәнрәк сеңде.

– Хәзер видеоконференциядә мине эт итеп сүктеләр! Вакцина ясату буенча план әлегә хәтле үтәлмәгән! Күрше оешмалар барысы да отчёт биргән. Ә без?!

Беренче итеп Дөмбаев социал мәсьәләләр буенча урынбасарын күтәрде.

– Синең барлык бюджеттагыларың кадатканнармы? – дип сорады ул аннан ачу белән.

– Бөтенесе дә түгел... – куырылып җавап бирде мескен.

– Ни сәбәптән? – дигән сорау бирде боргычлап башлык.

– Президентка сылтыйлар... – дип мыгырдады урынбасар. – Ул бу мәсьәләне ирекле дигән...

– Нәрсә? – башлык чәчрәп чыкты һәм карашын стенадагы портретка текәде. – Безнең әлегә үзебезнең президентыбыз бар! Кемнәр каршы килә, барысын да эштән читләштерергә!

– Ә кем дәвалый-укыта-өйрәтә? – дип сорау бирде урынбасар.

– Соңыннан аңлашырбыз! Хәзер төп мәсьәлә – отчёт тапшыру! Планны тизрәк тутыру өчен Казандагы кебек эшләргә кирәк – справкасыз һәм кодсыз автобуска кертүне тыярга!

– Җәяү йөри башлаячаклар. Аралар бит бездә башкаладагы кебек түгел... – дигән фикерен пышылдады транспорт җитәкчесе.

– Әле QR-кодлар да барлык кешедә юк, интернет та юньләп эшләми, әллә ничек эленеп кала!.. – дип тавыш салды цифрлаштыру урынбасары.

– Озакламый син үзең эленеп калачаксың! – диде аңа Дөмбаев чыгырыннан чыгып һәм боерыгын бирде.

– Кибетләргә, аптекаларга, мунчаларга һәм зиратларга справкасыз кертмәскә!

– Барыбер җаен табачаклар, – дигән шиген белдерде полиция начальнигы.

– Тыңламаучыларны тотсыннар, штраф салыгыз, бюджет тулыланыр!

– Тагын нинди тәкъдимнәрегез бар? – диде башлык кулындагы төерләре белән уйлап.

Залда үле тынлык урнашты. Ниһаять аны гомуми сораулар буенча урынбасар бозды.

– Аракы сатуны вакцина ясатмаганнарга тыярга кирәк!

Иелгән башлар күтәрелеп куйды.

– Ә нәрсә, әйбәт тәкъдим! – дип, җанлылык уянды барысында. – Безнең сәрхушләр бер шешә аракы өчен ун мәртәбә кадатырга әзерләр!

– Молодец! – дип куәтләп алды Дөмбаев урынбасарының тәкъдимен.

Ике көн дә үтмәгәндер, ул телефон буенча, бик канәгатьлек белән югарыдагыларга доклад бирде.

– Хәбәр итәм, миңа ышанып тапшырылган җирлектә вакцина ясату планы 104% итеп, арттырып үтәлде.

– Ә дүрт процентын кайдан алдыгыз? – дип гаҗәпләнделәр элемтә чыбыгының икенче очында.

– Безнең районнардагы халык бик аңлы! – дигән сүз аттырды башлык, тыйнаклык саклагандай. – Мондый халык белән 110% ка үтәп, теләсә нинди ковидны җиңәргә була!

БЕР ФИКЕРГӘ –
ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: Россиядә сайлаулар нәтиҗәсе бюллетеньнәрне ничек итеп саный белүдән тора.

Алмаз Хәмзин: Бу һәркемгә мәгълүм хакыйкать.

Р. Н.: "Санкция" дигән сүз хәзер бисмилла урынына әйтелә башлады түгелме?

А. Х.: Юк. "Пфф-ф!" урынына.

Р.Н.: Бүгенге байлар кәфенлекнең кесәсе булмавын, кабергә бер тиен дә алып керә алмауны беләләр микән?..

А. Х.: Беләләр. Шуңа күрә башта безне ачтан үтереп бетереп үлмәкче булалар.

Р. Н.: Авылда яшәп-эшләп ятучы гади бер крестьян, чиновникларга караганда, күпкә намуслырак булырга мөмкин.

А. Х.: Шикләнеп язма, турысын әйт, кайберәүләре: "Оятсызлар!" – диген.

Р. Н.: Алмаз туган, әгәр сиңа секретарь кыз, шофер, менеджер бирсәләр, син нишләр идең?

А. Х.: Син уйлаганча эшләмәс идем.

Р. Н.: Акчалар судан яки һавадан ясала торган булса, кешеләр ниләр генә кыланмас иде икән?!.

А. Х.: Соң, олигархлар шулардан ясый бит инде акчаны...

Р. Н.: Тәхеткә акыллы җитәкче килмәсә, илнең бәхете аксый.

А. Х.: Безнең бәхет гомергә аксак булды инде.

Р. Н.: Вакыт – даһи! Ул ел фасыллары белән бик төгәл идарә итә...

А. Х.: Ә менә президент сроклары белән идарә итә белми.

Р. Н.: Байлык югалырга мөмкин, ә акыл һәрвакыт үзең белән.

А. Х.: Акыллы булып та бай булырга мөмкинлек юк бит әле бу илдә.

Р. Н.: Кеше Марс планетасына аяк басса, могҗизаларга чик куелмас микән?

А. Х.: Анда да президентлар шушылар булачак бит инде.

Р. Н.: Кечкенә генә тишек зур корабны батыра ала.

А. Х.: Ямамасаң, әлбәттә...





Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Картлык галәмәте

Закир карт, уфтана-уфтана, шифаханәдән чыгып, автобус тукталышына юл тотты. "Әй бу табибләр берни дә белмиләр хәзер. Җитмәсә, үзләре бик яшь. Әле укыганнар микән – анысы билгесез", – дип уйланып барды ул.

Кирәкле автобуска утыргач, һаман уйларыннан туктамады. Транспортта кеше бик күп түгел, каршысына ике хатын-кыз туры килде.

– Мин кешегә тәкъдим итәр алдыннан белешәм: бәлки, аларга андый нәрсә ярамыйдыр, – диде берсе.

Закир карт, уйларыннан арынып, хатыннарның сөйләшүен тыңлый башлады. "Туктале, болар табиб түгел микән?" – дигән фикер килде аның башына.

– Дөрес әйтәсең, – дип, икенчесе кушылды.

– Әйе, бәлки, аларның берәр нәрсәгә аллергия бардыр. Аннары, ул бит балаларга да, олыларга да килешергә тиеш.

"Менә бит, бәхетемә каршы яхшы табибны каян табарга дигән идем, юлда очратырга насыйп булды", – дип, Закир карт сөенеп куйды. Ләкин ничек алар белән сүз башларга белмичәрәк калды.

– Минем шулай бер авыз пеште инде, берсенең аллергия булган икән. Ашыгыч ярдәм күрсәтергә туры килде.

– Гафу итегез, – дип сүзгә кушылды, ниһаять, Закир карт. – Сез миңа ярдәм итә алмассызмы?

– Нинди ярдәм кирәк сезгә, бабай?

– Менә, әле шифаханәдән кайтып килүем. Табибта булдым. Инде кайсына гына кермәдем. Берсе бер дару яза, икенчесе – икенчене. Аннары өченчесе миңа: "Бабай, юкка вакыт уздырып йөрмә, картлыктан дару булмый" – дип, өйгә кайтарып җибәрде. Шуңа борчылып кайта идем, менә, бәхетемә сез очрадыгыз.

Хатыннар бер-берсенә карашып куйды.

– Без ничек сезгә ярдәм итик соң, бабай? Без табиб түгел бит, – дип җавап кайтарды алар.

– Ничек инде табиб түгел? Шаяртмагыз. Мин үз колагым белән ишеттем бит, сез күп кешегә ярдәм иткәнсез. Аллергиясе булмасын, килешсен дигән сүзләрне.

Хатыннар көлешеп куйдылар һәм берсе:

– Бабай, син үпкәләмә, чынлыкта без табиб түгел. Дару, авырулар турында түгел сүзебез. Кызымның озаклмый туган көне. Шуңа нинди торт алырга икән дип сөйләшүебез иде. Хәзер бит, үзегез беләсез, җыен "ешка" тутыралар да, аннары олысының да, балаларның да аллергиясе барлыкка килә. Сатып алганчы, тортны әллә үзем ясыйм микән дигән уйга килгән идем.

– Анысы шулайдыр инде, шулайдыр, – диде Закир карт уфтанып. "Чыннан да, картлык инде бу, картлыктан дару юк, диләр. Кеше нәрсә сөйләгәнне белмичә сүзләрен бүлдем. Җитмәсә, үз тукталышымны да узып киткәнмен бит, ахмак".

Алдагы тукталышта төшеп, Закир карт өенә җәяү генә кайтып китте.



Вячеслав ШИЛОВ


Борис ДЁМИН



Владимир ТИХОНОВ



АРТТА КАЛУЧЫЛАР БЕЛӘН БЕРГӘ

Халыкара экспертлар Россия пенсия системасын дөньядагы иң начар системаларның берсе дип таныганнар. Узган ел илдә пенсия тупланмаларының уртача кереме елына нибары 0,2% тәшкил иткән. Бездән кала, Австралия, Чехия, Польша, Таиланд һәм Суринамада гына начаррак. Өйрәнелгән 70 ил арасында Мексика, Исландия, АКШ, Швейцария һәм Германия алдынгылар булып чыккан. Биредә күрсәткечләр – елына 3,2% тан 9,3% ка кадәр. Моннан тыш, Россия пенсия тупланмалары чит ил валютасына инвестицияләнми торган дөньядагы бердәнбер ил, димәк, акчаның бәясе төшүеннән якланмаган.

ШПИОН РИШВӘТЕ

17 нче Мордовиянең төзекләндерү колониясе башлыгы Владимир Денисов үз эш кабинетын җиһазландыру өчен, чит ил ярдәменнән файдаланырга карар иткән. Колониядә шпионаж өчен хөкем ителгән АКШ гражданинынннан смарт-телевизор, спутник телевидениесе комплекты һәм кесә телефоны таләп иткән. Тоткын бәхәсләшеп тормаган һәм үз хисабына полковникка кирәкле әйберне сатып алган. Ришвәт суммасы – 66 мең һәм моңа өстәп – җинаять маддәсе.

УТРАУ

Новосибирск өлкәсендә Искитим районының элеккеге башлыгы утрау саткан. Башта ул дача ширкәте өчен җир участогы бүлеп бирүне оештырган, аннары «дача иптәшләре» белән җир бәясен 6 тапкыр киметеп, сату-алу килешүен төзегән. Нәтиҗәдә, утрау 10 млн. сумга сатып алынган һәм ябык бистәгә әверелгән. Тикшерүчеләр элеккеге башлык сатылган җирнең рекреация зонасына керүен белми калмаган, һәм анда теләгән һәркем ял итә алуын белгән дип саныйлар.

ГӨМБӘЛЕ НАРКОТИК

Гади наркоманнар синтетик наркотик белән агуланган арада, галимнәр бер урында тормаган. Түбән Новгород вузларының берсендә өлкән фәнни хезмәткәрне фатирында псилоцин – наркотик матдә булган гөмбәләр үстергән өчен тоткарлаганнар. Гөмбәче үзе үстергән ризыкны куллануына карамастан, аңа сигез елга кадәр ирегеннән мәхрүм ителү куркынычы яный.



Юрий КУХАРЕНКО



Виктор ФЁДОРОВ

КАТАРСИС

Шамайны авылда шәп эретеп ябыштыручы буларак беләләр. Хәтта күрше авылларда да даны таралган иде. Тик бер бәласе бар – хәмер белән бик дус иде сварщик абзый. Әмма шул бәласен ул беркемгә дә сиздермәскә тырышты.

– Авырып киттем әле, хәлем начарланды, температура күтәрелде, – ди иде ул "авыру" чагында хәл белергә кергән дусларына. – Агуланганмын бугай... Әллә кичәге аш бозылган булган инде... – ул шулай – һаман яңа хәйләләр уйлап чыгара бирде.

Күршеләре аңа карыйлар да авыр сулап куялар: шундый ир әрәм була бит!

Яңа ел бәйрәме алдыннан укучылар катнашында концерт әзерләнде. Шамайның хатыны Мәрьям ай буе улы Камил белән Габдулла Тукай шигырен ятладылар.

– Үтенәм синнән, шушы атнада гына булса да эчми тор инде, – дип ялварды ул иренә. – Тиздән концерт, кеше алдында уңайсыз...

Ләкин Шамай түзмәде. Мәрьям шәһәргә әйберләр алырга киткәндә улын хәтта Мирзаһит белән калдырырга мәҗбүр булды. Балалар аның кызык такмакларын, җор әйтемнәрен, гыйбарәләрен тыңлап, көне буе күңел ачтылар.

Ниһаять Яңа ел концерты да килеп җитте. Бөтен авыл клубка җыелды. Шамай, тирә-юньдәгеләргә суламаска тырышып, мыштым гына хатыны янында утырды.

– Нәрсә, күрше, тагын авырып киттеңме әллә? – дип сорады аннан Юзим.

– Әйе, салкын тидергәнмен бугай, – диде теләр-теләмәс кенә Шамай һәм йодрыгына йөткереп куйган булды.

Сәхнәгә улы чыккач, Мәрьям күршесендәге хатынга пышылдады:

– Тукай шигырен яттан сөйләячәк! Ай буе ятладык!

Камил тамашачыларга баш иде дә микрофонга кычкырып әйтеп салды:

Аракыны-виноны
Бик яратам мин аны!
Яратмас идем дә, ләкин
Әти эчә бит аны!

Һәм кешенең шешәдән эчүен күрсәтте. Зал бер минутка шым булды, аннан соң, көлә-көлә, ярсып кул чабарга тотынды.

– Менә сиңа Тукай! – диде күрше хатын, Шамайга карап. Тегесе җир ярыгына кереп китәрдәй булган иде...

Кич белән мәктәп завучы Камил өчен бер кап тәм-том кертеп чыкты:

– Син аны ачуланма инде, Мәрьям, – дип үтенде ул. – Сәләтле малай үсә синдә!

Тиздән Камилнең ул такмакны Мирзаһиттан ишеткәнлеге ачыкланды. Һәм ул аны үз белдеге белән концертта сөйләргә булган. Гаҗәп, әлбәттә, ләкин шул көннән соң Шамай акылга утырды һәм эчүен ташлады.

– Сәнгать дәвалый дип, юкка гына әйтмиләр шул! – дип әтеп куя иде Мирзаһит, бу хәлне искә төшереп. – Кыскасы, катарсис!

Һәм тыңлаучыларга бу хикмәтле сүзнең мәгънәсен аңлатырга тотына иде...

Зөлфәт ШАҺИӘХМӘТОВ



Вячеслав ШИЛОВ

Борис СТАРЧИКОВ



Герман ОГОРОДНИКОВ



– Институтка уйнап кына кердем!

Рөстәм ЗАРИПОВ

МӘКТҮБЕ НИНДИ, МӘКТӘБЕ ШУНДЫЙ...

Калын томнар булып чыккан татар халык әкиятләре – Г. Ибраһимов исемендәге институт нык тырышкан. Татар халык әкиятләре атлы башка тупламнар да, бер камырдан "бии" бар да, уртак тамырга сырышкан... Хезмәт тора өч бүлемнән, хайваннар турында башта, тик тармадым ул эргәдә йолдыз кашка чабыш атка... "Әтәч белән төлке" дигән әкият ача ул бүлекне. Эчтәлек болай: әтәчкә мөрәҗәгать итә төлке: "Төш колгаңнан, намаз укыйк, яңартыйк без иманны", – ди. Әтәч әйтә: "Алай булгач, уят башлап имамны", – ди. Агач төбендә йоклаган эткә ымлый ул шым гына. "Кадалгыры, тәһарәтем ычкынды", – дип, төлке шыла... Әкиятнең икенчесе "Торна белән төлке" атлы, мәктәптә үткән Крылов мәсәленә нык ук тарткан... Өченче әкият "Аю, бүре, төлке" дип атала, имеш, шушы өчлек беркөн хаҗ сәфәренә юл ала. Ниятләре: "Киләчәктә бер затка да тимик", – була. Боларга дөя иярә, алар аны тотып суя... Дөянең эчәккарынын аю күлгә барып юа, күтәреләкүңелләре, чөнки тамаклары туя...

"Наян төлке" дигән әкият күпләргә ошыйдыр шаять, ике улын илтә бүре, төлкегә күп бүләк төяп. Мөгаллимә Төлкебикә, "укытам", дип алып кала, "ике атналык ризык", дип, нәни бүреләрне чала... "Нәзакәтле" әкиятләр тупланган шәлкемнән арып, әйдәгез, тылсымлы әкиятләр рәтенә барып карыйк... "Елан патшасы Шаһмара"... Шул патшаны егет исә, ут өстендә өч савытта кайнатам, дип, өчкә кисә... Икенче әкият – "Зөһрә", аның анасы бик "ушлый", күл төбеннән кара елан килеп чыккач, ыслыйыслый, кылыч белән чабып өзә шуның башын гаярь ана, бөтерелеп кала елан, үз әҗәлен шулай таба... Өченче әкият – "Каракош", иншамы соң дип торышлы, ул "Аленький цветок"ка нык охшаган, патамышты... Аның артыннан килгәне, "Балыкчы һәм гыйфрит" була, шуннан бер өзек китерик: "Патша улы сикереп тора. Хатын исә бутала һәм гыйфрит торды, дип куана, патша малае тота да бу гыйфрит хатынын чала..."

Адәм итенә мөкиббән диюләр күп бу бүлектә, турап өя әрдәнәләп диюләрне чос егетләр... Өченче бүлеккә баксак, анда мәзәкчелек көтә, иң алгы сызыкта Шомбай алдап-йолдап гомер итә... Анда тагын дин юлында йөргәннәрдән көлү шактый, мондый үрнәкләрне кемнәр укый икән мактый-мактый?.. Әкиятләр иң әүвәле җәлеп итә сабыйларны, татар балалары өчен шундый товар ярый ахры?

Мондый хезмәтләр иясе, исеме матур ИЯЛИ, түлке миндә бер вапрус бар, аны кемнәр соң иярли? "Фольклор"ны зачет өчен тәпәлиме студентлар? Җәүһәргә саныймы шуны духтыр илә кандидатлар? Титул-дәрәҗә алырга мондый "мал" торамы ярап? Фән диңгезендә йөзәме кораблары алга карап? Әләм теләп кулларына гавәм көтә микән дәвам? Шунда туктыйм, сынды каләм, хуш, вәкаләте вәссәлам..







• • •

Хәтерегездәме, Кашпировскийдан көлә идек барыбыз да, чөнки ул телевизордан дәвалый иде. Ә бүген табиблар телефон аша дәвалый һәм бу – гадәти гамәл...

• • •

Бер шулай Украина, Латвия, Литва, Эстония, Молдавия башлыклары бергә җыелганнар... Сорау: Нинди телдә аралашмакчы булалар икән алар?

• • •

Статистика буенча 80 яшьтән узган һәр ир-атка җиде хатын-кыз туры килә. Ләкин соң шул... бик соң...

• • •

– Исәннәрмесез! Сездә яшелчәләр өчен тартмалар бармы?
– Телевизормы?

• • •

Һәр кияүдәге хатын-кызны өйдә бәләкәч Нәрсәалдың һәм зур Нәрсәашыйм көтә. Тора-бара ул Нәрсәалдың, Акчабир булып үсеп җитә!

• • •

Совет заманында хайваннар өчен бер генә тапшыру бара иде, ул – "В мире животных" дип аталды. Хәзер андый программа юк, әмма аның урынына "Дом-2", "Давай, поженимся", "Прямой эфир с Андреем Малаховым", "Пусть говорят"... Иске программа миңа күбрәк ошый иде.

• • •

– Сез кайдан?
– Мәскәүдән.
– Хәзер бөтенесе Мәскәүдән! Төгәлрәк кайдан?!
– Бишкектан.

• • •

– Безнең оешма бик җитди. Әгәр безнеке булсаң, кире чыгу мөмкин түгел. Чыксаң, бары тик аякларыңны алга каратып кына.
– Кемнәр соң сез шундыйлар?!
– Пенсионерлар.

• • •

– Минем сездә бухгалтер булып эшлисем килә, эшкә йөрү графигы ничек?
– Ел буе, без әйткәнчә, тырышып эшлисең. Аннан соң өч ел утырасың – ял итәсең.



ГАДӘТИ КЫЕНЛЫКЛАР

Кадерле "Чаян"! Күп еллар буе без бистә юлларын төзекләндерүгә ирештек. Бигрәк тә сөенечебез "Васильево" санаториясе кырыеннан үтүче тимер юл белән ике арадагы юлга булды. Әйе, безнең теләкләр ишетелгән, һәм бу юлга яңа асфальт түшәлде, хәтта тротуар да барлыкка килде.

Шатлыгыбызның чиге юк иде, ләкин бу куаныч бер елдан озакка бармады. Көзен җылыту торбасында авария булу сәбәпле, яңа асфальтны рәхимсез рәвештә астын-өскә китереп ачтылар да, ике полосалы юл берлегә калды. Баштарак, машиналарга йөрү уңайлы булсын өчен, ремонтланасы җирне коймалап алдылар һәм әйләнеп узар өчен билге дә куйдылар. Ләкин ремонт эшләре тәмамлангач, ремонтлаучылары белән бергә коймалары, билгеләре дә югалды.

Гадәттәгечә куптарылган асфальтны төзекләндерү белән берәү дә шөгыльләнмәде. Бу урынны яктырту мәсьәләсе әлек тә каралмаган иде. Инде мондагы яшәүчеләр моңа күнеккән, сакланып, белеп йөриләр, ә менә сирәк килеп-китеп үтүчеләргә юлның кисәк тараюы һәм каткан балчык өемнәре – авария ясау өчен менә дигән сәбәп булып тора.

ВАСИЛЬЕВО бистәсендә яшәүчеләр

ЯШЕЛ ҮЗӘН районы

КАМАЛЫШТА

Хөрмәтле редакция! "Транспорт коллапсы" дигән мәгънә бар. Ул зур шәһәр араларындагы өзелмәс, шаулы автомобиль ташкынын тасвирлый. Без, Пермәк, Инеш, Пановка, Остачы бистәләрендә яшәүчеләр, бу күренеш белән бик таныш, гәрчә мегаполиска кертелмәсәк тә.

Эш шунда: автобуслар йөртүче оешма 113 нче санлы Пермәки–Казан маршрутын административ чикләүләр һәм кысулар аркасында эшләүдән туктатты. Шул сәбәпле, монда яшәүчеләр, беркая бара алмыйча, бикләнеп калды. Кайберәүләрнең район үзәгендәге Биек Таудагы поликлиникага да йөрисе бар, анда җәяүләп кенә барып җитү мөмкин нәрсә түгел. "Бомбил" машиналары бөтен кеше ихтыяҗын үтәп бетерә алмый, әле бит алар очсыз бәягә йөрми дә.

Транспорт министрлыгында безне тынычландыралар: имеш, яңа йөртүче оешма белән сөйләшүләр бара. Ләкин тәҗрибәдә – бөгелмәләләр мисалы моның киресен раслый – маршрутның яңартылуына өмет юк.

Хәтердә, Остачы бистәсе төзелгәндә, төзелеш оешмасы безне экоавыл итеп рекламалады. Хәзер безнең бистә тулысынча баштанаяк табигатькә чумды, тулы камалышта.

Пермәк, Инеш, Пановка, Остачы бистәсендә яшәүчеләр

БИЕКТАУ районы



Николай ВОРОНЦОВ



Вячеслав ШИЛОВ



Виктор ФЁДОРОВ

ЛӘБИБ ЛЕРОНга – 60!



Балакай чагымда безнең якларда хәерче Шакир бар иде. Салама киемдә, аркасында капчыгы – керәп-чыгып йөргән өйләрдән аңа ипи телемнәре, кабартма, пешкән бәрәңге, дучмак-коймактыр бирәп чыгаралар, ә инде кайберәүләр (хәллерәкләр) ашатып та озаталар иде. Кырынмаган да... "Рәхмәт, рәхмәт" дигән сүздән башканы белми дә иде бугай. Без – балалар аннан курка идек. Еллар узгач, Илһам Шакиров дигән бик шәп җырчы барлыкка килде. Мена шуның фамилиясе Шакиров булуына бик озак еллар күнә алмый йөрдем. Ләбиб Леронныкына – әйткән дә юк. Әле бит тәгал исеме Лемон икән... Андый исемле хәерче дә, хулиган да, бандит та юк югыйсә... Хан да, президент та, чурт та... Хәер, гафу, Ләбиб Айтуганов булган. Шагыйрь, журналист, драматург, композитор. Ләкин ул Леронов түгел... Баксаң, Ләбиб сүзе – сизгер, сак, үз көченә ышанучы, батыр дигән мәгънәләрне аңлата икән гарәпчә. Ләбиб Хабачи – Мисырның данлыклы галиме, Ләбиб Хәсәен әбү Роман – күренекле Израиль сәясәтчесе, ә менә хәзер үзебезнең күренекле Ләбиб Леронубыз бар. Татар язучысы, шагыйрь, журналист, Татарстан Язучылар берлегенең Шәйхи Маннур һәм Абдулла Алиш исемендәге, Республикабызның Муса Җәлил премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, 2013 елның декабреннән – "Безнең мирас" журналының баш редакторы. Шәп язучы! Исеменә күндем – хәзер иң якын дусларымның берсе! Юбилее уңаеннан бер шигырь дә яздым әле!

60 тулган Ләбиб Леронга!
Ник, дисезме?
Таза булганга!
Без котлыйбыз Аны "Чаян"да,
Ул бит үткен телле, шаян да!

Шундыйларны "Чаян" ярата,
Шундыйлар гел илне агарта.
Җәмгыятьне чирдән тазарта,
Вәхшилеккә кискен сүз ата!

Алмаз ХӘМЗИН

ЛӘБИБЧӘ ӘЙТЕЛГӘН ГЫЙБАРӘЛӘРНЕҢ БЕРНИЧӘСЕ

• • •

Бер тапкыр үлгәнче, мең тапкыр көлүең яхшы.

• • •

Өйдә бер термос була торып, балама Термос дип исем кушмам бит инде.

• • •

Без шундый халык: без сатылмыйбыз, безне сатып кына алалар.

• • •

Синең татарча әйткәнеңне ишетмәмешкә салынган кеше үз телен белмәгән татар булыр.

• • •

Маңкорт татарга чит тел якынрак.

• • •

Авыру илдә сәламәт яшәп булмый.

• • •

Чит-ят хатыннарның ысылдавына караганда, үз хатыныңның өрүе җанга якынрак.

• • •

Гашыйк булган саен шигырь язса, кәгазь җитмәс иде шагыйрьгә.

• • •

Җирдә йолдыз шулхәтле күбәйде, күктәгесенә багарга һич вакыт юк.

РОБАГЫЙЛАРДАН БЕР-ИКЕСЕ:

И татарым, хәлләр беркем кызыкмаслык:
Бер үк тырма тешләренә кырык бастык...
Үзебезчә сөйләшергә һич юк вакыт:
Кияү – урыс, килен – марҗа, онык – маңкорт!

Бу Рәсәйне ваклап сатып эчтеләр, дип
Кемдер анда, кемдер монда сөйләнә бик.
"Монда минем өлеш тә бар!" – дип уйласаң,
Кысылмыйча кала күрмә син дә, Ләбиб.

КӨЛЕМСӘК МӘЗӘКИЯТЛӘРДӘН – ИКЕСЕ

СИН ИДЕҢМЕНИ?

– Бүген командировкадан кайтып керсәм...
– Ха-ха-ха!..
– Ник көләсең? Әле сөйли генә башладым бит...
– Ха-ха-ха-ха... Бәй, син идеңмени ул?.. Ха-ха-ха...

КАЙСЫГЫЗ МИНЕМ ӘТИ?

(Кәмит)

Кыз. Сиңа әйтәм! Безнең балабыз булачак! Ишеттеңме, Рәис?!

Егет. Ишетәм лә-ә-ә... Чукрак түгел. Әтисе кем? Нәсимме?

Кыз. Аңламассың сезне! Нәсим син дип уйлый... Гали – Нәсим дип...

ШАКМАКЛЫ ТАКМАКЛАРЫНЫҢ – ДҮРТЕСЕ

ЭШЛӘПӘ

Һич кенә дә тынгы бирми
Бер сәер теләк:
Кояшны эшләпә итеп
Киясе килә.

БЕР ФИКЕР

Язалар да сызалар –
Әдәбият чүбәя...
Шагыйрьләр кимегән саен,
Редакторлар күбәя.

КАЙ ЗАМАН БУ

Интернет заманы шул,
Карыйсың көлеп кенә...
...Тукайдан калган каләмнең
Карасы кибеп килә...

СЕЗ СОРЫЙСЫЗ...

"Хәлең ничек?" –
дип сорыйсың...
Хәлләр чыдарлык кына:
Җирдән күтәрелеп булмый
Һава чыгарып кына.

ПАРОДИЯЛӘРНЕҢ – ӨЧЕСЕ

Гәрәй РӘХИМГӘ

Шагыйрь ул, язучы, лауреат...
Исем бар, дәрәҗә бар, әйе.
Титулы гына ни тора:
Советлар Союзы Гәрәе!

Равил ФӘЙЗУЛЛИНГА

(Улы Газизне истә тотып)
Кырыклап китабы чыккан –
Иллегә тулмагае...
Фәйзуллинның шәп китабы
Газизе булмагае!

МИҢА ДА БЕРНЕ ЧӘПЕГӘН

Брежневларны "терелттең"...
"Шикәр" сөйләп көлдерттең...
Җырлар җырлап, юмор көйләп...
Язучы булып беттең!

ЖУРНАЛЫБЫЗ ИСЕМЕННӘН, ХӨРМӘТ ИТЕП:

Ләбибнең маңгайга чәпеп
Язганнарын аңлыйбыз.
"Чаян"ыбыз югарак шул –
Барсын сыйдыралмыйбыз...

Амур Фәләх

Калышаммы соң?!

Эштән кайтып киләм. Бигрәк авыр булды бүген. Хезмәт хакы бирделәр. Югыйсә шатланасы гына иде дә бит. Юк шул, "хәерчегә җил дә каршы" дигәндәй, кытыршы телләре белән сыер ялап алган кебек, кәеф юкка чыкты. Гомер булмаганны, үз эшемнән тыш, тиешле эш сәгате тәмамланса да, вазыйфама туры килмәгән әллә нинди эшләр башкарырга туры килде. Житәкче "үтенечен" берсүзсез үтәргә кирәклеген яхшы белсәм дә, "Моның өчен миңа, һичьюгы, өстәмә түләнер микән?" – дип сорарга батырчылык иттем. "Син, нәрсә, иптәшең авырып киткән, кеше хәленә керергә кирәк, шуның исәбенә байыйсың киләме?!" – дип кенә җикерде хуҗа. Әйтерсең миңа акча кирәкми! Әйтерсең анда – өйдә һәр тиенне санап утыручы хатыным юк!..

Бу хуҗадан котылып, өйдәге хуҗабикә кулына килеп кергәнче, бераз ял итеп алырга исәп. Кыска юлны озынайтып, юлда очраган эскәмияләргә утырып ял итә-итә, урап-урап кайтам. Кайтып кергәч тә хатынымның сүз башын бик яхшы күз алдына китерәм. Бу һәрвакыт бертөсле: юынып, бер чынаяк чәйне тотып, телевизор каршына килеп утыруым була, артыма килеп басып башын минем иң өстенә сала да, хәйләкәр елмаеп: "Җаным! Беләсеңме, нәрсә, Вәли..." – дип, моңлы тавышларын сибә башлый.

Ялгыша күрмәгез, Вәли – мин түгел. Безнең белән бер йортта яшәүче "заочный" танышым. Кайсыдыр заводта эшли һәм, хатынның әйтүенә караганда, менә дигән ир, эшкә батыр, акчаны көрәп ала, тиктормас бер бәндә булырга тиеш.

Хатынымның мине Вәли белән беренче таныштыруын әле дә хәтерлим. Әнә шулай телевизор каршына килеп утыруым булды, артымнан килеп кочаклады да очлы ияген янбашыма төртте:

– Беләсеңме, нәрсә, Вәлияләргә кергән идем, ире Вәли аяк киемнәре тезеп кую өчен ишектән керүгә тумбочка шикелле бер нәрсә ясап куйган. Уңайлы да әйбер инде, бөтен вак-төякне шунда тутыралар икән. Теләсәң, син дә ясый аласың инде аны. Вәлидән киммени минем ирем, ә?

Тумбочканы, әлбәттә инде, ясап куярга туры килде. Дөрес, минем, Вәли шикелле, тактасын, тегесен-монысын култык астына кыстырып, көнгә ике тапкыр алып кайтырга мөмкинлегем юк. Мин эшләгән җирдән каләм, кәгазь кыстыргыч, бетергеч алып кайтсаң гына инде. Алар белән тумбочка ясап буламыни? Әмма нишләмәк кирәк, ясап куйдым тумбочканы. Вәлидән калышаммы соң!

Китте шуннан.

– Беләсеңме, нәрсә, Вәли лоджияларын пыялалап куйган. Шундый шәп килеп чыккан, җил дә исми, кошкортлар да очып йөрми, яңгыр да сиптерми. Теләсәң, син дә эшлисең инде аны. Кай төшең Вәлидән ким синең?

Кредит алсам алдым, әмма тиздән безнең дә балкон пыялаланды. Ә нәрсә, минем дә Вәлидән ким җирем юк...

– Вәли ишекләре өстенә җыйнак кына сәндерә ясап куйган...

Вәлигә генә дигәнмени? Хәзер безнең дә ишек өстендә шүрлек бар.

– Вәли ванна белән бәдрәф арасындагы җөйне әйбәтләп цемент белән томалап куйган...

– Вәли, астына киез салып, ишекләрен тышлаган. Суык та керми, тыштагы тавыш та ишетелми...

– Вәли фәлән, Вәли төгән...

Мин дә калышмыйм. Хатыным ахирәте Вәлияләргә кереп йөрүен туктатканчы бу мөмкин дә түгел. Менә бүген дә дустымның чираттагы этлегән көтеп кайтам. Бәрепләр үтерәсе килә үзен, диган фетнәле уй башка кереп утырды. Беркөнне ит чабарга дип балта кайрый башласам, күз алдымда – Вәлинең пеләшләнеп ялтырый башлаган баш түбәсе тора. Алла сакласын!.. Тфү, тфү!

...Ялгышмаганмын, бүген дә шул ук хәл. Эш киемнәрен салып ташлап өй халатын кидем дә, чәй әзерләп, телевизор каршына килеп утыруым булды – колак төбемдә хатынымның бәрхет тавышы:

– Ишеттеңме әле, Вәлиләр аерылыша икән бит. Гариза биргәннәр инде.

Мин "ә" дип берара авызымны ачып утырдым да сикереп торып язу өстәленә ташландым. Бер бит чиста кәгазь алып, уң як өске почмагына: "Халык судына. Гариза", – дип язып та куйдым.

Ә нәрсә, Вәлидән кай җирем ким минем?!



Ринат МИРЗАЯНОВ



САТИРА һӘМ
ЮМОР ЖУРНАЛЫ
1923 елдан чыга.

№ 12 (1913) декабрь 2021

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре,
Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләре агентлыгы
ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы,
йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша
язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның
ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү
хокукына ия.


«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 03.12.2021 ел.
Тираж – 3963 Заказ Е-3965

Редакциянең адресы: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмалар өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!



Ринат АБЗАЛОВ төзеде.



1. Ни өчен психиатр белән бәхәсләшү кыен?

2. Нәрсә ул тормыш тәҗрибәсе?

3. Сәбәпсез көлү нәрсәне аңлата?

4. Кешеләр нигә вакцина ясата?

5. Дага элеп кую бәхет килүне аңлатамы?

6. Юл уңмау нәрсә ул?

7. Чын ялгызлык кайчан килә?

ҖАВАПЛАР

1. Чөнки сез аңа фикер әйтәсез, ә ул сезгә диагноз тукылдый. 2. Тырмага басканда син инде башыңа каска кигән! 3. Начальнигыңның мәзәгенә исең китү. 4. Байлар – ресторанга йөрү өчен, ярлылар – эшкә бару өчен. 5. Юк. Ул камытны салгач килә. 6. ГАИ хезмәткәрләре сине пунәтәй булыр өчен туктата, ә син – исерек. 7. Башыңа бер фикер дә килми башлагач.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чайнвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 11 нче санындагы чайнвордның тикшерү сүзе – **«КИТМӘ МИННӘН»**.

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),

А. ГАФИЯТУЛЛИН (Норлат р-ны, Кычытканлы ав.),

Б. ШӘЙХЕТДИНОВ (Алексеевский р-ны, Урта Тигәнәле ав.),

С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Кычытканлыдан

Азат ГАФИЯТУЛЛИН!

ШАЯН БӨРТЕКЛӘР


Николай ВОРОНЦОВ


Александр ЛЕВИТИН


Виктор ФЁДОРОВ

Николай ЧЕРНЫШОВ




Василий АЛЕКСАНДРОВ

Анастасия ВАСИЛЬЕВА



